ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРАЗБАХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРАЗБАХТЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Советская, д.1а, с. Уразбахтино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422155

Совет ур., 1 нче а йорт, Уразбахты авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422155

тел.(факс): (85563) 2-86-36; e-mail: UrBah.Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
08.11.2019 ел

Карар
№ 26

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы Уразбахты авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын
җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Уразбахты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге 2019 елның 7 нче ноябрь 1 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге составына керүче Уразбахты авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны үз контролемә алам.

Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе /Р.Г.Шәйхетдинов/

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге Башкарма комитетының 08.11. 2019 ел. 26нчы санлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Уразбахты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2020 елның 26 нче мартына кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, түли.

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль

районы Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге
Башкарма комитетының
8 нче ноябрь 2019 ел,
26 нчы санлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш Муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге
(*муниципаль берәмлек иселе*)

бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
________________________________________________________________________________
________________________________________________________
Адрес: ________________________________________________________

Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2020 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 26.03.2020 елда халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр 500сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: <u>УФК по РТ (Финансово-бюджетная палата Мамадышского муниципального района РТ)</u>

Кабул итүче як банкы
Сч. №
Кабул итеп алучы Сч. № ________________________________________
ИНН
КПП
КБК
ОКТМО
Түләүнең билгеләнеше: Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче _________________ ________________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -
________________________________________________________
(*муниципаль берәмлек иселе*)
________________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _________________
Түләүченең Ф.И.Ә.и. ________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________________
«__» _______________ 20__ г. ________________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)________________ авыл җирлеге Башкарма комитетында тотырыла һәм кала.*